РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№15

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Тимершык авыл җирлеге Советының 23.03.2013 елгы
15 номерлы карары белән расланган Тимершык авыл
җирлегендә гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган
торак биналарны муниципаль милеккә тапшыру тәртибе
турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы акчаларын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында»гы 01.03.2020 елгы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 23.03.2013 елгы 15 номерлы «Гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны Тимершык авыл җирлегенә муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турында" гы карары белән расланган Тимершык авыл җирлеге Советы тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны гражданнар тарафыннан муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.1.пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Хосусыйлаштырылган торак урыннарны Тимершык авыл җирлеге муниципаль милкенә тапшырырга теләгән гражданнар, Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитетына торак урынының барлык милекчеләре тарафыннан имзаланган, гражданның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар. Гаризага муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә торган документлар теркәлә.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы

Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы Хаҗ А.Х. Хаҗиев